РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕЩЕРЯКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАРЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

06 апрель 2022 ел

№ 9

Язгы чорда Карлы авыл җирлегенең җирле
әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап
транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча
чикләү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы карары, Карлы авыл җирлеге уставы нигезендә, уңайсыз табигый-климат шартлары барлыкка килгән чорда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының конструктив элементларының яраксызлану мөмкинлеген киметүне булдырмау максатларында Буа муниципаль районы Карлы авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Бюрган авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап 2022 елның 1 апрелennән 30 апреленә кадәр транспорт чарасы күчәренә туры килә торган 6 тоннадан артык массалы транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне (алга таба - язгы чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү) кертергә.

2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Буа районы буенча ЮХИДИ бүлегенә Буа муниципаль районының Карлы авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү режимын үтәүне тикшереп торуны оештырырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге мәгълүматны Карлы авыл җирлегенең торак пунктларында, шулай ук эре габаритлы авыр йөкле транспорт чараларының милекчелек яисә башка өстенлекле хокукы нигезендә булган оешмаларда яшәүчеләргә җиткерергә.

4. Әлеге карар Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиешле вакыттан законлы көченә керә, шулай ук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районы Карлы авыл
җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе

Д.Х. Абдрахманов